ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУТЛУШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯҮШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

улица Г.Исхакый, дом 9,
с.Кутлушкино,Чистопольский район

Г.Исхакый урамы, 9 йорт,
Яүширмә авылы,Чистай районы

тел.(84342) 3-40-42,тел/факс 3-40-42,E-mail:Kutl.Ctp@tatar.ru

КАРАРЫ

2019 елның 24 декабре №8

Чистай муниципаль районының
Яуширмә авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Яуширмә выл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Яуширмә авылы гражданнар җыенының 2019 елның «07» ноябрендәге 1 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Яуширмә авыл
җирлеге башлыгы Л.Р.Гәрәева

Чистай муниципаль районы
Яуширмә авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 8 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Яуширмә авыл җирлеге ражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Яуширмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Яуширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль
районының
Яуширмә авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Яуширмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
__________________________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________
_______________________________________________________________ нигезендә
Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
түбәндәге реквизитлар буенча:_________________________________________________
Алучы Банк БИК ______________________________________
Сч. № __________________________________
Алучы Сч. № _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләү билгеләү
__________________________________________________________________________
Җитәкче __________________ ________________________________________
М.П. (имза) (тулы имза)
- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -
хәбәр (хәбәрнамә) № _____
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф. И. атасының исеме __________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. ______________________________________
(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше Яуширмә авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.